ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» декабрь 2020 ел № 428

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының күпфатирлы йортларына карата региональ
оператор счетында капиталь ремонт фондын булдыру ысулы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 7 пункты, 181 статьясы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, “Капиталь ремонт фондын төзү ысулы турында законнарда билгеләнгән срокларда һәм күпфатирлы йортларны тиешенчә тоту һәм төзекләндерү сыйфатын арттыру максатларында карар кабул итмәгән Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларның милекчеләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасының «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан аларда урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайламаган яисә алар сайлаган ысул гамәлгә ашырылмаган күпфатирлы йортларга карата региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды төзергә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән карары турында хәбәр итәргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
22.12.2020 № 428
карарына кушымта

**Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлар исемлеге**

| № | Район | Адрес |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе муниципаль районы | ТР, Әгерҗе ш., Энергетиклар ур. 2а |